ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
КАЛМАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**КАРАР**

“02” ноябрь 2020 ел Калмаш авылы №4

**“Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлегенең Калмаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы “Калмаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2020 елның 13 ноябрендә 13.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Калмаш авылы Зөфәр Галиев урамында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2020 елның 17 ноябренә 18.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Калмаш авылы Гагарин, Зөфәр Галиев, Үзәк, Советлар урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә
3. 2020 елның 18 ноябренә 18.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Калмаш авылы Яңа, Сәйдәш, Тукай урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә
4. 2020 елның 19 ноябренә 18.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Калмаш авылы Каенлы, Дуслык,, Салимгараев, Чияле, Тынычлык, Litbox Кояшлы, Күл буе, Төн як, Лазурная, Җиңүгә 70 ел, Фатих Амирхан, Чәчкәле, Муса Җәлил, Якут Метшин, Яшьләр, Төзүчеләр, Урманлы, Болынлы, Басу урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын билгеләргә.
5. Калмаш авылында яшәүчеләрнең исемлеген сайлау тәртибе халык җыенын үткәрү өчен территориаль билге буенча башкарырга
6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Калмаш авыл җирлегенең Калмаш авылы территориясендә 2021 елда балигъ булган, Калмаш авыл җирлегенең Калмаш авылы территориясендә яшәү урыны

буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

- Калмаш авылында юлларны төзекләндерү;
- юлларны төзекләндерү өчен вак таш, асфальт түшәк сатып алу һәм кайтару;
- Калмаш авылында электроматериаллар сатып алу, урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыруны;
- Калмаш авылы Зөфәр Галиев урамы буенча урнашкан канализацияне реконструкцияләү һәм материаллар сатып алу;
- Калмаш авылы зиратын койма белән уратып алу өчен материаллар сатып алу һәм урнаштыру;
- Калмаш авылында язгы ташу вакытында су басуны булдырмау өчен су бүлү каналларын эшләүне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме

“ӘЙЕ” “ЮК”.

7. Җыенның дүрт этабын да түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай районы, Калмаш авылы, Центральная урамы, 32 нче йорт, «Яшьлек»мәдәният йорты.

8. Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

9. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

10. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында “авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

11. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Калмаш авыл җирлеге
Башлыгы Р.К.Габдуллина